**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2026 елның 2 марты 19 -РС номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының һәм Лаеш шәһәре «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе балансындагы муниципаль мөлкәтне «Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә түләүсез файдалануга тапшыру турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, район Советының 2010 елның 23 июлендәге 24 номерлы карары белән расланган Лаеш муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында нигезләмә нигезендә, Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. ТР, Лаеш муниципаль районы, Имәнкискә авылы, Совет ур., 23А йорт адресы буенча урнашкан 15,4 кв. м мәйданлы бинаны (алга таба - Учреждение) «Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (алга таба-Учреждение) әлеге карарга кушымта нигезендә бер елга түләүсез файдалануга тапшырырга.
2. Учреждениегә бер ай эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе белән мөлкәтне түләүсез файдалану шартнамәсе төзергә һәм аны килештерү өчен Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тапшырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Лаеш муниципаль районы Советының
2026 елның _ -номерлы карарына кушымта

**«Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә түләүсез файдалануга тапшырыла торган муниципаль мөлкәт исемлеге**

| N т/б | Инвентарь һәм кадастр номеры | Объектның исеме һәм характеристикасы (катлылык, төзелеш материалы һәм башкалар). | Урыны (адресы) | Саны | | | | Кертеп тапшыру (сатып алу) елы | Бинаның беренчел-торгызу бәясе, мең сум. | Тузуы | | Калган бәя мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Данә якипог.м | Мәйданы кв.м | | | | | % | Мең сум. | |
| | | | | | Техник паспорт буенча урталык | файдалы | янкорма | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | | Административ бина бүлмәсе | Лаеш районы, Имәнкискә ав., Совет ур., 23а й. | 1 | 15,4 | | | 2018 | 16213,96 | 28,33 | 4593,96 | 11620,00 |